КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 28 сентябрь г.Казань № 919

Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт (контроле) күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт (контроле) күзәтчелеге турындагы нигезләмәне расларга.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлашты-

руга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2015 ел, 3 ноябрь, 832 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 ноябрь, 832 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 11 ноябрь, 863 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2015 ел, 3 ноябрь, 832 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 18 декабрь, 1170 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 3 ноябрь, 832 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объектлары, җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары торышына, эчтәлегенә, аларны саклауга, файдалануга, популярлаштыруга һәм дәүләт саклавына төбәк дәүләт күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 1 сентябрь, 767 нче карары.

3. Бу карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин